ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Постановление*** | ***Карар***

**2021 елның 21 мае** | **Чистай шәһәре** | **№ 271**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 сентябрендәге 473 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында.

Чистай шәһәр прокуратурасының 2021 елның 19 маендагы 02-08-02-2021 номерлы протестын карап чыкканнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 сентябрендәге 473 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсендә муниципаль сәясәт өстенлекләре» бүлегенең 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2019-2021 еллар»;

1.2. «4. Программаның төп чаралары һәм гамәлгә ашыру механизмы» бүлегендә «йорт китабыннан яки финанс-шәхси счеттан өземтә, фатир картасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. Программада «3. Программаның төп чаралары һәм гамәлгә ашыру механизмы» бүлеген «4» бүлеге дип санарга.

1.4. Программада «4. Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр» бүлеген «6» бүлеге дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов